ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

______________ с. Верхний Услон ______________

Җир эшләрен җитештерүгә ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Югары Ослан муниципаль районы хакимияте органнарының физик һәм юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын күтәрү максатларында һәм тышкы төзекләндерү кагыйдәләре белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен исәпкә алып,Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставы белән Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Җир эшләрен җитештерүгә ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга.
2. «Җир эшләрен җитештерүгә ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 29 мартындагы 756 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге начальнигына әлеге карар белән расланган муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын үтәүне тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль-икътисади үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Л.С. Хакимзянов